Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Иске Куак авыл җирлеге
Иске Куак авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 21 ноябре № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлегенең Иске Куак авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Куак авыл җирлеге Иске Куак авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда гражданнарның үзара салымын Лениногорск муниципаль районы Иске Куак авыл җирлеге Иске Куак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм хәрби хәрәкәттә катнашучылар, тыл хезмәтчәннәре, сиксән яшьтән өлкән гражданнар һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру һәм суүткәргечләрне алыштыру.

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге - төзекләндерү һәм вак таш салу.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36, Зеленая урамы,7 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Куак авыл җирлеге башлыгы И.Н.Сушкова